*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 46**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) сөт
   ә) боз
   б) бозау
   в) төлке

2. Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) урамнар
   ә) көнгерә
   б) көнбагыш
   в) әнкәй

3. Омонимнарның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Урам буйлап атлы кеше бара. – Авылда Мостафа атлы карт яши.*
   а) саф лексик
   ә) омоформалар
   б) омофоннар
   в) омографлар

4. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) көчек
   ә) балакай
   б) белем
   в) исем

5. Җөмләдәге сүз төркемнәрен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Җәен йоклама, кышын өлгерерсең.* (Мәкаль).
   а) исем, боерык фигыль, исем, хикәя фигыль
   ә) рәвеш, боерык фигыль, рәвеш, хикәя фигыль
   б) рәвеш, боерык фигыль, рәвеш, боерык фигыль
   в) рәвеш, хикәя фигыль, рәвеш, хикәя фигыль

6. Тезүче теркәгечне билгеләгез. **(2 балл)**

а) дип
ә) өстендә
б) ләкин
в) чөнки

7. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Матурлык күлмәк белән сәдәптә түгел, оят белән әдәптә*. (Мәкаль).

а) матурлык
ә) күлмәк
б) сәдәптә
в) оят

8. Кушма җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Матур гөл чәнечкеле була. (Мәкаль).
ә) Май чүлмәге тышыннан билгеле. (Мәкаль).
б) Начар кеше кеше кулы белән елан тотарга ярата. (Мәкаль).
в) Үзең киясе киемеңне үзең сайла. (Мәкаль).

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган авазны һәм сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

[н] авазы, [къ], [к], [гъ], [г] авазлары алдыннан килгәндә, [ __ ] авазы булып укыла. _________ иҗекле сүзгә басым билгесе куелмый._____________ – тотрыклы сүзтезмә. Сүзнең ____________ кисәкләрен сүз төзелеше өйрәнә. Саннар исемнәргә һәм ____________ ияреп килә ала. Эш-хәлнең ничек үтәлү-үтәлмәвен белдереп килә торган иярчен кисәк ____________ хәле дип атала.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(12 балл)**

*Золотой подснежник*

*После холодной, суровой зимы все ждут весну. Кто открывает весну?*

*Весну открывает ранний первенец цветов – мать-и-мачеха. Этот золотой подснежник растёт на солнечных глинистых склонах. Мать-и-мачеха распускается раньше всех трав, до вылета первых пчёл, до ледохода.*

*Цветёт этот чудесный цветок около двух месяцев.* (К. Пронин).

2. Сез кайсы ел фасылын яратасыз һәм ни өчен? Шул хакта 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп языгыз. **(12 балл)**